Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге
Пимәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

21 ноябрь, 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Пимәр торак пунктында 2025 елның 21 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 191 (йөз туксан бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 99 (туксан тугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 99 (туксан тугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2026 елда Пимәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов